# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«25» ноябрь 2022 ел № 8

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Пичментау авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 25 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Пичментау авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 400 сум, 1 нче һәм 2 нче төркем инвалидларга, 75 яшьтән узган гражданнарга, көндезге формада белем алучы студентларга 200 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- рөхсәтсез чүплекне рекультивацияләү;

- җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең юл полотносы нигезләү һәм каплау: Җиңү урамы;

- зиратны тоту өчен җиһазлар сатып алу (кәбер казу өчен отбойный молоток – 1 данә)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 85 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 46 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 43 кеше тавыш бирде;
“Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 3 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Печмәнтау авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Пичмәнтау авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 400 сум, 1 нче һәм 2 нче төркем инвалидларга, 75 яшьтән узган гражданнарга, көндезге формада белем алучы студентларга 200 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;

- рөхсәтсез чүплекне рекультивацияләү;

- җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең юл полотносы нигезләү һәм каплау: Җиңү урамы;

- зиратны тоту өчен җиһазлар сатып алу (кәбер казу өчен отбойный молоток – 1 данә)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип таныргa.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Печмәнтау авылы, Җиңү урамы, 22 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Хабибуллин